
# Һөнәр

**Кешенең төп шөгыле, эше, хезмәте.**

- Аш пешерүче Төзүче Тегүче Сыер савучы











- Хат ташучы Янгын сүндерүче Чәч алучы Очучы









# Ребус



- Морҗа чистартучы



- Аяк киеме чистартучы



- Су ташучы



- Фонарьчы



# Мәкальләр

- Эшчән кеше – имәндәй, Ялкау кеше – яфрактай.
- Барын да беләм дигән берни дә белмәс.
- Хезмәт төбе – хәзинә.
- Эшләп ашасаң тәмле булыр.
- Вәли үз эшендә, Гали үз эшендә.
- Агач җимеше белән, адәм эше белән.
- Эш беткәч уйнарга ярый.
- Һөнәрле үлмәс, һөнәрсез көн күрмәс.

# Күп нокталар урынына тиешле сүзләрне куегыз

- ... балык тота.
- ... матур рәсемнәр ясый.
- ... киемнәр тегә.
- ... балалар өчен әкиятләр яза.
- ... бакчада чәчәкләр утырта.
- ... кызыклы гәҗитләр тарата.
- ... биек йортлар төзи.
- ... кешеләрне дәвалый.

( төзүче, язучы, табиб, балыкчы, хат ташучы, тегүче, бакчачы, рәссам )

# Дөрес итеп языгыз

| Кем?<br>(Кто?) | Кайда?<br>(Где?) | Нишли?<br>(Что делает?) |
| --- | --- | --- |
| УКЫТУЧЫ<br>(учитель) | ФАБРИКА<br>(на фабрике) | ДӘВАЛЫЙ<br>(лечит) |
| САТУЧЫ<br>(продавец) | ЗАВОДТА<br>(на заводе) | УКЫТА<br>(учит) |
| ТЕГҮЧЕ<br>(портниха) | МӘКТӘПТӘ<br>(в школе) | ТӨЗИ<br>(строит) |
| ЭШЧЕ<br>(рабочий) | КИБЕТТӘ<br>(в магазине) | ТЕГӘ<br>(шьет) |
| ТАБИБ<br>(врач) | ТӨЗЕЛЕШТӘ<br>(на стройке) | САТА<br>(продает) |
| ТӨЗҮЧЕ<br>(строитель) | ХАСТАХАНӘДӘ<br>(в больнице) | ЭШЛИ<br>(работает) |

# Рәсемнәрнең парын тап




















## “Доктор.“ Р. Миңнуллин

Малайлар, юкка сез
Доктордан куркасыз
Бик әйбәт ул, димен:
Әни бит ул минем.

## ”Шофёр булам” З. Туфайлова

Мин дә әтием шикелле
Шофёр булырга уйлыйм.
Шуның өчен мин һәрвакыт
Машина белән уйныйм.
Тизрәк үсеп шофёр булсам,
Нишләргә белер идем:
Урамдагы бар баланы
Утыртып йөрер идем.

## ”Минем әби” М. Садри

Минем әби бик уңган,
Ул укытучы булган.
Ул укыткан балалар
Зур үскән инде, алар
Төрле һөнәр беләләр:
Кукуруз үстерәләр,
Казанда - алар мехчы,
Химик, шофёр, сабынчы,
Металлист һәм тегүче,
Ә Җәлилдә - төзүче.

## ”Һаҗирә апа.” М. Садри

-Ә менә минем апа
Конфет-прәник сата
Ул эшләгән кибеттә
Бар ак күмәч тә, сөт тә.

## ”Әнием һөнәре.” Ф. Яруллин

Минем әнием тегүче,
Үз эшен бик нык сөя,
Ул теккән җылы киемне
Бик күп кешеләр кия.